**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2022 елның «28» апреленнән № 139

Макулатура һәм полиэтилен җыю буенча «Чиста авыл синнән башлана!» конкурсының нигезләмәсен раслау турында

Торак пунктларның экологик торышын яхшырту, ишегалларын һәм урамнарны чистарту максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

Кушымтада бирелгән макулатура һәм полиэтилен җыю буенча «Чиста авыл синнән башлана!» конкурсының нигезләмәсен расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына конкурста җиңүчеләрне бүләкләү өчен 20 000 (Егерме мең) сум акча бүлеп бирергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында (http://novosheshminsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Расланган
Татарстан Республикасы
Яңа Чшмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «28» апреленнән
139 номерлы карары белән

Макулатура һәм полиэтилен
җыю буенча «Чиста авыл синнән башлана!» конкурсының нигезләмәсе

Макулатура һәм полиэтилен җыю буенча муниципаль конкурс (алга таба-Конкурс) үткәрү турында әлеге нигезләмә аны оештыру һәм үткәрү максатларын, бурычларын, тәртибен билгели.

1. Гомуми нигезләмәләр

Конкурс Яңа Чишмә муниципаль районында экологик хәлне яхшыртуга юнәлтелгән.

2. Максатлар һәм бурычлар

2.1. Конкурс Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктларының ишегалларын һәм урамнарын макулатура һәм полиэтиленнан чистарту максаты белән үткәрелә.

2.2. Конкурсның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

муниципаль бюджет белем бирү учреждениеләре (алга таба-МБГБУ) укучыларын туган авылны экологик чистарту буенча гамәли эшчәнлеккә җәлеп итү;

яшь буында әйләнә-тирә мохитнең чисталыгы өчен җаваплылык хисе формалаштыру;

район халкы арасында культура дәрәҗәсен күтәрү;

икенчел чималны рациональ куллану.

3. Конкурста катнашучылар

3.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениеләре укучылары.

4. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм сроклары

4.1. Конкурсны үткәрү вакыты 2022 елның 1 маеннан 2022 елның 31 маена кадәр

.

4.2. Макулатура, полиэтилен җыю Яңа Чишмә муниципаль районы белем бирү учреждениеләре укучылары тарафыннан башкарыла.

4.3. Картон һәм кәгазь (газета, А4, журнал) җыю аерым башкарыла.

4.4. Полиэтилен җыю аерым чүп-чар өчен пластик капчыкларга башкарыла.

4.5. Макулатура, полиэтилен массасын үлчәү икенчел чимал кабул итү пунктлары башкара.

4.7. Макулатура һәм полиэтиленны илтеп тапшыруны мәгариф оешмалары башкара.

## 5. Конкурста катнашучыларны бүләкләү

Конкурста җиңүчеләр (сыйныф) конкурста катнашучы сыйныф укучылары исеменә, Яңа Чишмә муниципаль районы белем бирү учреждениеләре укучылары тарафыннан икенчел чималны кабул итү пунктында тапшырылган икенчел чимал күләме турында документлар нигезендә билгеләнә. Урыннар 1000 килограммнан да ким булмаган икенче чимал җыйган һәм тапшырган сыйныфга бирелә.

1 урын-9000 сум
2 урын-7000 сум
3 урын-4000 сум